ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.12.2022 г. Казань № 698-132/тэ-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 25 маендагы 56-8/тэ-2022 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 7 декабрендәге 42-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Казаньнефтепродукт» филиалы «Татнефтепродукт» ХК акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга, җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2021-2023 елларга тарифлар билгеләү хакында» 05.11.2020 № 152-9/тэ-2020;

«Казаньнефтепродукт» филиалы «Татнефтепродукт» ХК акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче, җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 05.11.2020 № 152-9/тэ-2020 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 ел өчен үзгәреш кертү хакында» 10.11.2021 № 252-39/тэ-2021.

2. Әлеге карар 2022 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев